КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 1 декабрь г.Казань № 1074

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хисап елы өчен Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә мониторинг йомгаклары һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган күрсәткечләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү хакында» 2013 ел, 27 май, 355 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хисап елы өчен Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә мониторинг йомгаклары һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган күрсәткечләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү хакында» 2013 ел, 27 май, 355 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 24 февраль, 109 нчы; 2017 ел, 31 май, 326 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары арасында бүленә торган, Хисап чорына Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингы нәтиҗәләре һәм өч еллык чорга аларның планлаштырылган мәгънәләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладына кертелә торган хисап чорына Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен каралган күрсәткечләр исемлегендә:

I бүлекнең 8 пунктындагы 8.6 пунктчада «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлекнең 22 пунктында «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлектә:

23 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктка түбәндәге эчтәлекле 23.1 пунктча өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «23.1. | Укучыларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче укучылар өлеше, процент | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы»; |

VI бүлекнең 25 пунктындагы 25.1 пунктчасында «- 3 ел эчендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

IX бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 41 пункт һәм 41.1 – 41.3 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «41. | Муниципаль оешмалар тарафыннан мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәләрендә һәм тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан һәм әлеге өлкәләрдә муниципаль берәмлекләр бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән әлеге өлкәләрдә хезмәт күрсәтүче бүтән оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайт мәгълүматлары буенча) (булганда): | |
| 41.1. | мәдәният өлкәсендә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 41.2. | мәгариф өлкәсендә | Татарстан Республикасы |

| | | |
|---|---|---|
| | | Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 41.3. | социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча)»; |

әлеге карар белән расланган Хисап чорына Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингы нәтиҗәләре һәм өч еллык чорга аларның планлаштырылган мәгънәләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладын структурасында һәм эчтәлегендә X бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«X. Йомгаклау

Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләүне үз эченә ала.».

2. Бу карарның 1 пунктындагы унынчы – унҗиденче абзацлары 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин